ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 605 31 июль, 2018 ел

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә эшләмәүче халыкка шәхси саклану чаралары бирү өчен территориаль нокталар булдыру турында

“Гражданнар оборонасы турында” 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законы, “Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән халыкны һәм территорияне саклау турында” 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы үтәлеше өчен, “Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау турында” 2007 елның 26 ноябрендәге 804нче номерлы Россия Федерациясе хөкүмәте карары, «Халыкны шәхси саклану чаралары белән тәэмин итүне оештыру нигезләмәсен раслау турында” 2014 елның 1 октябрендәге 543нче номерлы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыгы һәм “Шәхси саклану чараларын, радиацион, химик тикшерү һәм контроль җайланмаларын куллану кагыйдәләрен раслау һәм куллануга кертү турында” 2003 елның 27 маендагы 285нче номерлы Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыгы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районында эшләмәүче халыкка хәрби хәрәкәт алып барган вакытта яки әлеге хәрәкәт аркасында куркыныч янаганда халыкны саклау максатында, һәм шәхси саклану чараларын вакытында бирү өчен, карар бирәм:

Түбән Кама муниципаль районында эшләмәүче халыкка шәхси саклану чаралары бирү территориаль нокталары булдырырга.

Шәхси саклану чараларын чыгару һәм китерү өчен йөк төяү-бушату командалары оештырырга.

1. Расларга:

1.1. Түбән Кама муниципаль районында эшләмәүче халыкка шәхси саклану чаралары бирү территориаль нокталары булдыру нигезләмәсе (1нче кушымта).

1.2. 1.1. Түбән Кама муниципаль районында эшләмәүче халыкка шәхси саклану чаралары бирү территориаль нокталары исемлеге (2нче кушымта) .

1.3. Йөк төяү-бушату командалары составына эшчеләр бирүче оешмалар исемлеге (3нче кушымта).

2. Шәхси саклану чаралары бирү нокталары булдыручы оешма һәм предприятие җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

2.1. Карар кабул ителгәннән соң ике ай вакыт эчендә шәхси саклану чаралары бирү нокталарының эш өчен кирәкле документаль базасын эшләргә.

2.2. Шәхси саклану чаралары бирү нокталарының оештыру-штат структурасын, аны комплектлаштыру тәртибен һәм ачуга әзерлекне боерык белән расларга.

2.3. Боерык күчермәләрен Түбән Кама муниципаль районы буенча Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсенә җибәрергә.

2.4. Халыкка шәхси саклану чаралары бирү нокталары эшен Түбән Кама муниципаль районында эшләмәүче халыкка шәхси саклану чаралары бирү территориаль нокталары булдыру нигезләмәсе һәм Татарстан Республикасы буенча Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының баш идарәсе шәхси саклану чаралары бирү нокталары булдыру һәм эшен оештыру методик тәкъдимнәре ярдәмендә оештырырга .

2.5. Ел саен, "Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты" муниципаль унитар предприятиесе белән берлектә, эшләмәүче халык исемлеген ачыклау.

3. Йөк төяү-бушату командалары булдыручы оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

3.1. Карар кабул ителгәннән соң ике ай вакыт эчендә йөк төяү-бушату командаларына эшчеләр бирү турында боерык чыгарырга.

3.2. Боерык күчермәләрен Түбән Кама муниципаль районы буенча Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсенә җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы буенча Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсенә шәхси саклану чаралары бирү нокталарын булдыру мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты” муниципаль унитар предприятиесе директорына эшләмәүче халыкка шәхси саклану чараларын алу вакыты һәм урыны турында адреслы хәбәр итүнең тәртибен һәм вакытын билгеләргә.

6. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади прогноз, транспорт һәм элемтә бүлеге башлыгына шәхси саклану чараларын халыкка адреслы җиткерү өчен транспорт бүлүне исәпләргә һәм складлардан алып бирү пунктларына кадәр шәхси саклану чараларын китереп җиткерү өчен транспорт бирүче оешмаларны билгеләргә.

7. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлегенә әлеге карарның басма матбугатта һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

8. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М.Шәйдуллинга йөкләргә

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

1нче кушымта

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 31 июлендәге
605нче номерлы карары белән
расланган

Түбән Кама муниципаль районында эшләмәүче халыкка шәхси саклану чаралары бирү буенча территориаль нокталар булдыру турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге нигезләмә “Гражданнар оборонасы турында” 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законы, “Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән халыкны һәм территорияне саклау турында” 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законы, “Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау турында” 2007 елның 26 ноябрендәге 804нче номерлы Россия Федерациясе хөкүмәте карары, «Халыкны шәхси саклану чаралары белән тәэмин итүне оештыру нигезләмәсен раслау турында” 2014 елның 1 октябрендәге 543нче номерлы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыгы һәм “Шәхси саклану чараларын, радиацион, химик тикшерү һәм контроль җайланмаларын куллану кагыйдәләрен раслау һәм куллануга кертү турында” 2003 елның 27 маендагы 285нче номерлы Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыгы нигезендә һәм Түбән Кама муниципаль районында эшләмәүче халыкка шәхси саклану чаралары бирү территориаль нокталары булдыру нигезләмәсе һәм Татарстан Республикасы буенча Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының баш идарәсе шәхси саклану чаралары (алга таба - ШСЧ) бирү нокталары булдыру һәм эшен оештыру методик тәкъдимнәре нигезендә эшләнгән.

ШСЧ бирү нокталары Түбән Кама муниципаль районының эшләмәүче халкына гражданнар оборонасы милкен әзерләү һәм бирү өчен билгеләнгән.

ШСЧ бирү ноктасы ул - күрсәтмә алуга, милекне саклау складларыннан алып халыкка тулысынча биргәнче үз функцияләрен үтәүче вакытлыча оешкан формирование.

ШСЧ бирү ноктасының шәхси составы алар базасында булдырылган предприятие, учреждение яки оешма (алга таба – оешма) җитәкчесе боерыгы белән билгеләнә. Шәхси состав ел саен чираттагы елның 1 гыйнварына булган мәгълүматлар буенча билгеләнә.

Эшләмәүче халык шәхси саклану чаралары белән республика запасларыннан тәэмин ителә.

Эшләмәүче халыкка керә: эшләмәүче пенсионерлар, хезмәт инвалидлары , балачактан инвалидлар һәм алар белән яшәүче эшсез һәм балигъ булмаган аларның гаилә әгъзалары, исемлекләр төзү көненә балалар бакчаларына, мәктәпләргә һәм уку йортларына йөрми торган балалар.

ШСЧ бирелергә тиешле затларның исемлеге ШСЧ бирү нокталарының администрациясе тарафыннан тыныч вакытта «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесе белән берлектә төзелә һәм ел саен чираттагы елның 1 гыйнварына булган торышына аныклана.

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади прогноз ясау, Транспорт һәм элемтә бүлеге халык яши торган урыннарга адреслы илтү өчен транспорт бүлүне исәпләп чыгара һәм складлардан ШСЧ бирү нокталарына шәхси саклану чараларын китереп җиткерү өчен транспорт бирүче оешмаларны билгели.

Бина әзерләү, аларны җиһазлау, тарату нокталарының шәхси составын өйрәтү һәм күнегүләр үткәрү формированиеләрне өйрәтүнең уку планы буенча тыныч вакытта гына башкарыла. Ноктаны әзерләү һәм аның эше өчен җаваплылык аның базасында төзелә торган оешма җитәкчесенә йөкләнә.

Саклау складларыннан ШСЧын алып чыгу өчен көч һәм чараларны әзерләү, милекне саклау складларыннан чыгару һәм гражданнар оборонасы милкен бирү беренче чираттагы гражданнар оборонасы чараларын үтәүгә күрсәтмә алу белән башкарыла. ШСЧ бирү ноктасында 1 сәгать эчендә кимендә 180-200 противогаз бирү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

Бирү ноктасына беркетелгән халыкны ШСЧ белән тәэмин итү эшләре тәмамланганнан соң, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсенә гражданнар оборонасы милкен бирүгә ведомость кушымтасы белән хисап тапшырыла.

## 2. ШСЧ бирү ноктасы документлары

2.1. ШСЧ бирү ноктасы булдыру һәм ноктаның шәхси составын билгеләү турында оешманың гражданнар оборонасы җитәкчесе боерыгы.

2.2. Ноктаның урнашу планы (схемасы) һәм кирәкле җиһазлар исемлеге

2.3. ШСЧ бирү ноктасы шәхси составының штат-вазыйфаи исемлеге.

2.4. Вазыйфаи затларның функциональ бурычлары.

2.5. Противогаз белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлеге.

2.6. ШСЧ бирү ноктасын әзерлеккә китерү планы.

2.7. ШСЧ бирүгә ведомость бланклары

2.8. Хәбәр итү һәм шәхси составны җыю схемасы.

2.9. Боерык кабул итү журналы.

2.10. Телефон белешмәсе (шәһәрнеке).

2.11. Противогазларны сайлау һәм җайлау буенча белешмә мәгълүматлар.

2.12. ШСЧ куллану кагыйдәләре буенча кулланма.

2.13. ШСЧ бирү ноктасының эшкә әзерлек планы ул төзелә торган оешманың җитәкчесе тарафыннан раслана.

Документларны турыдан-туры эшләп чыгару белән оешма җитәкчесе боерыгы белән билгеләнгән ШСЧ бирү ноктасы җитәкчесе шөгыльләнә.

## 3. ШСЧ бирү ноктасы составы

Оешма мөмкинлекләренә, аның исемлектәге санына карап, ШСЧ бирү пункты түбәндәге составта булырга мөмкин:

3.1. ШСЧ бирү ноктасы башлыгы.

3.2. Звенолар:

- ШСЧ бушату (звено җитәкчесе, йөкчеләр);
- ШСЧ бирү (звено җитәкчесе, тарату буенча инструктор, ШСЧын җыю һәм тикшерү, ШСЧын куллану кагыйдәләренә өйрәтү буенча инструктор);
- ШСЧын кулланырга әзерләү (звено җитәкчесе, противогазларның алгы өлешләрен сайлау буенча инструктор , ШСЧын сортларга аеручы);
- ШСЧна техник тикшерү (звено җитәкчесе, инструктор-химик, табиб (фельдшер).

## 4. ШСЧ бирү ноктасы вазыйфаи затларының функциональ бурычлары.

4.1. ШСЧ бирү ноктасы башлыгының функциональ бурычлары.

ШСЧ бирү ноктасы башлыгы оешманың вазифаи затларыннан билгеләнә һәм аның җитәкчесенә буйсына, ноктаның эшкә әзерлеге өчен җавап бирә.

ШСЧ бирү ноктасы башлыгы вазыйфасы:

а) тыныч вакытта:

- әлеге ноктада бирелә торган ШСЧның санын һәм төрләрен белү.;
- ШСЧ бирү ноктасы өчен биналарны, кирәкле җиһазларны һәм документларны әзерләргә;
- функциональ вазыйфаларын үтәү өчен, ШСЧ бирү ноктасының шәхси составын укытырга;
- ел саен агымдагы елның 1 гыйнварына ШСЧ бирү ноктасының штаттагы вазифаи исемлеген һәм шәхси составын, хәбәр итү схемасын аныклау, тәгаенләнгән мәгълүматларны Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсенә җибәрергә ;

б) чыгару өчен күрсәтмә алган вакытта:

- «Беренче чираттагы гражданнар оборонасы чаралары»н үтәүгә күрсәтмә алуга, һәм ШСЧын чыгарырга команда булуга, хәбәр итәргә һәм ШСЧ бирү ноктасының шәхси составын җыярга.;
- 4 сәгатьтән соң ШСЧын кабул итү һәм складлау өчен ноктаны әзерләргә;
- ШСЧын кабул итүгә, аларны нокта бинасына бушатырга, кабул итүгә документлар рәсмиләштерергә һәм оешма җитәкчесенә хәбәр итәргә.
- ШСЧын төрләр буенча урнаштырырга һәм ышанычлы саклауны тәэмин итәргә;
- ноктаның шәхси составы белән функциональ вазыйфаларын үтәү буенча практик дәрес үткәрергә;

в) "Гражданнар оборонасына гомуми әзерлек” чараларын үтәүгә күрсәтмә алуга, шәхси саклану чараларын бирүне оештырырга:

- хәбәр итү үткәрергә, ноктаның шәхси составын җыярга, 4 сәгатьтән соң аны тулы схема буенча эшләү өчен җәелдерергә;
- шәхси составка инструктаж үткәрергә һәм аның эше белән җитәкчелек итәргә;
- противогазлар алырга килгән затларны каршы алуны оештырырга һәм бирүне исәпкә алырга;

- эшләмәүче халык (картлар, инвалидлар) өчен, кирәк булганда, противогазларны яшәү урыннарына китерү буенча чаралар күрергә;

- противогазларны бирү тәмамланганнан соң, оешма җитәкчесенә хәбәр итәргә;

- Түбән Кама муниципаль районы буенча Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсенә хисап документларын тапшырырга.

4.2. Бушату звеносы җитәкчесенең функциональ бурычлары.

Бушату звеносы җитәкчесе бирү ноктасы башлыгына буйсына һәм нокта эшләү барышында аның күрсәтмәләрен үти.

Бушату звеносы җитәкчесенең бурычлары:

- бирү ноктасына китерелгән милекне вакытында төяү һәм бушату эшләрен оештырырга;

- бирү төркеменә ШСЧын өзлексез китерүне тәэмин итәргә;

- эшләрне башкарганда, куркынычсызлык чараларын үтәүне тәэмин итәргә, тартмаларны ачу өчен кирәкле инструмент булдырырга;

- эш тәмамланганнан соң. бушаган тараны һәм калган милекне бирү ноктасы җитәкчесе күрсәткән урыннарга тапшырырга.

4.3. ШСЧ бирү звеносы җитәкчесенең функциональ бурычлары.

ШСЧ бирү звеносы җитәкчесе бирү ноктасы башлыгына буйсына һәм нокта эшләү барышында аның күрсәтмәләрен үти.

ШСЧ бирү звеносы җитәкчесе бурычлары:

- ШСЧның төзелешен, эш принцибын, җайлау кагыйдәләрен белү, герметиклыкка тикшерү һәм алардан файдалана белү;

- төркемнең шәхси составы бурычларын билгеләү һәм аныклау, тыныч вакытта шәхси составка функциональ бурычларын үтәү өчен кирәкле күнекмәләр үткәрү;

- ШСЧның размерларын билгеләү өчен кирәкле әйберләр булу;

- килгән халыкка ШСЧның барлык төрләрен дөрес сайлау мөмкинлеген карау;

- үз билгеләнешләре һәм үлчәмнәре нигезендә ШСЧын дөрес сортларга аеру белән җитәкчелек итү;

- куркынычсызлык чараларын һәм шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту.

4.4. ШСЧын куллануга әзерләү звеносы җитәкчесенең функциональ бурычлары.

ШСЧын әзерләү звеносы җитәкчесе иң әзерлекле вазифаи затлардан билгеләнә, бирү пункты башлыгына буйсына һәм пункт эшләү чорында төркемнең шәхси составы өчен турыдан-туры җитәкче булып тора.

ШСЧын куллануга әзерләү звеносы җитәкчесе бурычлы:

- төркемнең шәхси составын белү һәм аны функциональ бурычларын үтәргә әзерләү;
- ШСЧның төзелешен, эш принцибын, җайлау кагыйдәләрен белү, герметиклыкка тикшерү һәм алардан файдалана белү;
- ШСЧын дөрес җыю һәм җайлауны контрольдә тоту;
- противогазларның алгы өлешен дезинфекция эремәсе белән эшкәртүне контрольдә тоту;
- килгән халыкны ШСЧын куллану кагыйдәләренә өйрәтү;
- шәхси составның эшенә җитәкчелек итү, куркынычсызлык чараларын һәм шәхси гигиена таләпләрен үтәүне таләп итү;
- эш тәртибен бозу очраклары турында бирү ноктасы башлыгына хәбәр итү.

4.5. ШСЧна техник тикшерү үткәрү звеносы җитәкчесенең функциональ бурычлары.

ШСЧна техник тикшерү үткәрү звеносы җитәкчесе бирү ноктасы башлыгына буйсына, шәхси составның эшен җитәкли һәм противогазны дөрес җыюны һәм төзек булуын тикшерә, ярсыткыч матдә белән эшләгәндә, куркынычсызлык чараларын үтәү өчен җавап бирә.

ШСЧна техник тикшерү үткәрү звеносы җитәкчесе бурычлы:

- төркемнең шәхси составын белергә һәм аны җыюны җитәкләргә;
- ярсыткыч матдә (хлорпикрин, хлорацетофенон) белән эшләгәндә, куркынычсызлык чараларын белергә;
- торак биналардан 100 метрдан да якынрак булмаган арада палатка урнаштырырга (бина булдырырга) ;
- ярсыткыч матдә булган палаткада (бүлмәдә) противогазның алгы өлешен сайлау һәм төзеклеген тикшерү үткәрергә;
- техник тикшерү һәм противогазларны җайлау вакытында җил юнәлешен даими контрольдә тотарга кирәк;
- противогазларга тикшерүне палаткада хлорпикрин парлары концентрациясе 8,5 мг/л булганда үткәрергә;

- җитешсезлекләр ачыкланган очракта, противогазны төзәтергә яки алгы өлешен алыштырырга һәм кабат тикшерү үткәрергә.

Шәхси саклану чараларын бирү пунктын вакытында җәелдерү, ШСЧын китерү, шулай ук шәхси состав формированиесе тарафыннан ШСЧын бирү кагыйдәләрен  ныклы белү билгеләнгән вакытта халыкның барлык категорияләренә ШСЧын бирергә мөмкинлек бирәчәк.

2нче кушымта

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 31 июлендәге
605нче номерлы карары белән
расланган

Түбән Кама муниципаль районында эшләмәүче халыкка шәхси саклану чаралары бирү территориаль нокталары (ШСЧ БН)

исемлеге

| № ШСЧ БН | ШСЧ БНын җәелдерүгә җаваплы оешма | Аның базасында ШСЧ БН җәелдерелгән объект | ШСЧ БНна беркетелгән адреслар |
|---|---|---|---|
| 1 | “Түбән Кама механика заводы” АҖ | 12нче мәктәп, Спорт урамы, 21а, (8555) 39-35-20, 42-80-14<br>(1нче номерлы ҖЭН каршында) | Гагарин урамы, 2, 2а, 4, 8,<br>Спорт урамы, 19, 19а, 21, 23,<br>Вахитов проспекты, 8/14, 13а, 17, 19, 19а, 21/10,<br>Чәбия урамы, 1/25, 3, 5, 5а, |
| 2 | «Шинник» СКХК ҖЧҖ | 5нче мәктәп, Бызов урамы, 9а (8555)36-47-85,43-75-44<br>(2нче номерлы ҖЭН каршында) | Шинчылар проспекты, 47, 51, 53, 55, 57,<br>Бызов урамы, 6, 9,11,11а,13,17,10, 12, 14,15, 16, 18,<br>Менделеев урамы, 32, 32б, 34, 36, 36а,<br>Урман урамы 43,45 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | “Түбән Кама нефтехим” ГАЖ | 1нче мәктәп, Төзүчеләр проспекты, 9 (8555) 43-76-65 (3нче номерлы ҖЭН каршында) | Тукай урамы, 2,4,6 8,10,12, 14, 16, 22, 24, Төзүчеләр проспекты, 4, 4а, 4б, 5, 6, 6б, 7, 8, 8а, 8б, 10,11, 11а, 11б, 11в, 13, 13а, 13б, 13в, Актүбә (барлык йортлар) |
| 4 | «Түбән Кама шин» ГАЖ | 22нче мәктәп, Менделеев урамы, 15а, (8555) 36-74-06 (4нче номерлы ҖЭН каршында) | Вахитов урамы, 12, 12а, 14, 16, Химиклар проспекты, 86, 88, 90, Гагарин урамы, 13, 15, 17, 19, 19а, 19б, 19 в, 21а, 21б, 23, Менделеев урамы, 11, 13, 13а, 17 |

| № ШСЧ БН | ШСЧ БНын җәелдерүгә җаваплы оешма | Аның базасында ШСЧ БН җәелдерелгән объект | ШСЧ БНна беркетелгән адреслар |
|---|---|---|---|
| 5 | «ТР ТКМР Башкарма комитеты мәгариф идарәсе” | 14нче лицей, Яшьлек урамы, 34, (8555)30-56-24, 30-56-17 (5нче номерлы ҖЭН каршында) | Вокзал урамы, 30, Химиклар проспекты, 16, 16б, 16г,18а, 20, 18б, 20а, 20в, 22, 24, Яшьлек урамы,32, 36, 36а, 36б, 33, 35, 37 |
| 6 | “Түбән Кама нефтехим” ГАЖ | 15нче мәктәп, Кайманов урамы, 4 (8555) 43-42-35, 36-64-89 (7нче номерлы ҖЭН каршында) | Кайманов урамы, 2/18, 6, 8,12, 14, 18, 18а, Менделеев урамы, 12, 14, 16, Гагарин урамы, 27, 29, 31, 35, 35а, 37,41, 41а, 45 |
| 7 | «Түбән Кама шин» ГАЖ | 20нчы мәктәп, Гагарин урамы, 42 (8555)36-64-90, 36-64-89 (9нчы номерлы ҖЭН каршында) | Гагарин урамы, 34, 36, 38, 44, 46, 48, 52, 54, Менделеев урамы, 2, 2а, 2б, 4, 4а, 6, 8, Урман урамы, 1, 1а, 5, 7, 9, 11, 13/50, Яр урамы (барлык йортлар) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | “Шәһәр электр транспорты” МУПсе | Знче мәктәп, Мәктәп буль-вары, 2, (8555) 41-69-44, 41-6946<br>(10нчы номерлы ҖЭН каршында) | Төзүчеләр проспекты, 20а, 22, 22а, 24, 26, 28,<br>Тын аллея урамы, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 11, 12, 13,<br>14, Химиклар проспекты, 54, 56, 58, 58а, 60,<br>Мәктәп бульвары урамы, 3, 3а, 4,6,8,9,11/1,7/2, Октябрьнең 50 еллыгы урамы, 2а,3,4,5,6,7, 9, 11, 13, 15, 17, 19, 21,23/62 |
| 9 | «ТТКХ һәм Т департаменты» МУПсе<br>(«Кама» ТКХ ИК ҖЧҖ) | 25нче гимназия, Шинчылар проспекты,<br>60, (8555) 39-08-97, 39-12-20<br>(13нче номерлы ҖЭН каршында) | Урман урамы, 27,<br>Химиклар проспекты, 81/24, 83, 87,95, 97,<br>99, Шинчылар проспекты, 44, 46, 48, 50, 54, 56,64/29, 66, Менделеев урамы, 24а ,26 |
| 10 | «ТТКХ һәм Т департаменты» МУПсе,<br>(«Вокзал» ТКХ ИК ҖЧҖ) | 19нчы мәктәп, Химиклар проспекты, 8б,<br>(8555) 30-02-11 (14нче номерлы ҖЭН каршында) | Химиклар проспекты, 2, 4, 6, 6а, 8, 8а, 12, 12а, 12б, 14б, 14в, 14, 14а,<br>Афанас урамы (тулысы белән),<br>Субай урамы (тулысы белән),<br>Чулпан урамы (тулысы белән),<br>Вокзал урамы, 32, 34, 36, 38 с,<br>Зур Афанас |

| № ШСЧ БН | ШСЧ БНын җәелдерүгә җаваплы оешма | Анның базасында ШСЧ БН җәелдерелгән объект | ШСЧ БНна беркетелгән адреслар |
|---|---|---|---|
| | | | с. Нижнее Афанасово |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 | «Эластик заводы» ҖЧҖ | 32нче гимназия, Сөембикә урамы, 38, (8555) 39-66-45 (16нчы номерлы ҖЭН каршында) | Бакый Урманче урамы, 14, 20, 22, 24, 28, Тынычлык проспекты, 37, 43, 52, 57, 58, 62, 63, 61, 64, 66/2, Шинчылар проспекты, 1, 3, 3а, 3б, 3в, 5, 7, 9, 11, 13, 13а, 15, 17, 23, Сөембикә урамы, 4, 6, 9, 11, 12, 13, 14, 16, 20, 22, 24, 26, 28, 30, 32, 34, 36, 42, Кояшлы урамы (тулысы белән), Төзүчеләр проспекты 84Д, 84Е |
| 12 | «Түбән Кама индустрия техникумы» ДАҺББУ | Түбән Кама индустрия техникумы, Химиклар проспекты, 29, (8555) 30-18-32 (17нче номерлы ҖЭН каршында) | Студентлар урамы, 16, 18, 25, 27, 27а, 29, 29а,31,35, Җиңүнең 30 еллыгы урамы, 3,7, 9,11,15, 17, 19, 21, Химиклар проспекты, 31, Корабельная урамы, 30, 36, 38, 40, Ильинка авылы, Дмитриевка авылы |
| 13 | «ТАИФ-НК» ААҖ | 31нче мәктәп, Тынычлык урамы, 16 (8555) 36-57-46, 36-38-88 (18нче номерлы ҖЭН каршында) | Тынычлык проспекты, 6, 8, 10, 14,18, 20, 22, 24, 24а, 26, 28, 30, 32, 38, 38а, 40, 42, 44, 46, 48, 50, Сөембикә, 44, 50,52, 56, 58, 60, 62, 64, 66, 68, 72, Чулман урамы, 2, 4, 6, 8, 10, 12, 14, 16, 1, 3, 5, 7, 11,15, 17 |
| 14 | «ТСНХРС тресты» ҖЧҖ | 33нче мәктәп, пр. Химиклар проспекты, 13 (8555) 30-10-53 (19нчы номерлы ҖЭН каршында) | Корабельная урамы, 27, 29, 31, 35, 37, 39, 41, 43, 45,51, Студентлар урамы, 30, 32, 32б, 36,34, 35, 47, 49, 51, 59, 61, 63, Химиклар проспекты, 1, 1а, 1б, 3, 5, 7, 9, 9б, 9в, 15, 17, 21, 23, 25 Южная урамы (тулысы белән), Р.Гайнуллин урамы, 4,6, 8, 10, 14, 16, 18, 20, 23 |

| № ШСЧ БН | ШСЧ БНын җәелдерүгә җаваплы оешма | Аның базасында ШСЧ БН җәелдерелгән объект | ШСЧ БНна беркетелгән адреслар |
|---|---|---|---|
| | | | Фикрәт Тәбиев урамы, 1, 3, 5, 7, 9, 11, 13, 15, 17, 19,21, 23, 25, 27, 29, 31,<br>Җиңүнең 30 еллыгы урамы, 25, 27, 29, 28, 30, Төзүчеләр проспекты, 59, 61 |
| 15 | “Түбән Кама нефтехим” ГАҖ | 7нче мәктәп, Бызов урамы, 18б (8555) 36-94-46, 36-95-03<br>(20нче номерлы ҖЭН каршында) | Шинчылар проспекты, 61, 63, 67, 69, 71, 73,75, 79,81, Бызов урамы, 22, 22а, 24, 24а, 24б, 26, 28, 30, 32/38 |
| 16 | “Түбән Кама нефтехим” ГАҖ | 11нче мәктәп, Гагарин урамы, 1в (8555)43-97-90, 39-52-36<br>(21нче номерлы ҖЭН каршында) | Спорт урамы, 13, 13а,15,17, 17а, Химиклар проспекты, 70а, 70б, 70в, 70г, 70д, 72а, 72б, 72в, 72г, 72д, 76а, 76, 76в, 76г, 76д, 78а, 78б, 78в, 78г,<br>Гагарин урамы, 1, 1а, 1б, 3, 3а, 3б, |
| 17 | «Камэнергостройпром» ААҖ | 2нче мәктәп, Яшьлек урамы, 4<br>(8555) 43-18-24 (22нче номерлы ҖЭН каршында) | Төзүчеләр проспекты, 15, 17, 19, 21, 23, 25, 27, 29, 31, 33, 33а<br>Тукай урамы, 26, 30, 32, 34, 36, 38, 40,<br>Яшьлек урамы, 1, 3, 3а, 3б, 5, 6, 8, 9, 9а, 9б, 9в, 10, Химиклар проспекты, 44, 46, 46а, 46б, 48, 50, 52 |
| 18 | «НТЦ Кама» ААҖ | «Шинник» спорткомплексы, Гагарин урамы, 32, (8555) 41-29-96, 41-29-97 (23нче номерлы ҖЭН каршында) | Корабельная урамы 1, 3, 5, 7,11, 11а, 13, 15, 15а, 15б, 19, 21, 21а, 21б, 25, Вокзал урамы, 18, 28, Яшьлек урамы, 25 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 19 | «Түбән Кама йөк шиналары заводы» ААҖ, СЦ №1 | 1нче татар гимназиясе, Гагарин урамы, 5в, (8555)39-5237, 39-52-39 (24нче номерлы ҖЭН каршында) | Вахитов проспекты, 23, 25а, 27а, 27б, 31а, Гагарин урамы, 5, 5а, 5б, 7, 7а, 9, Химиклар проспекты, 80а, 80б, 80в, 82а, 82б |
| 20 | «ТР ТКМР Башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» | 21нче мәктәп, Мурадьян урамы,18а (8555) 36-12-30, 36-61-40 (25нче номерлы ҖЭН каршында) | Мурадьян урамы, 4, 4а, 6, 8, 8а, 10, 12, 14, 16, 16а, 18, 20, Бызов урамы, 1, 1а, 3, 5, 5а, 7, 7а, 7б |

| № ШСЧ БН | ШСЧ БНын җәелдерүгә җаваплы оешма | Аның базасында ШСЧ БН җәелдерелгән объект | ШСЧ БНна беркетелгән адреслар |
|---|---|---|---|
| 21 | “Түбән Кама нефтехим” ГАҖ | 29нчы мәктәп, Тынычлык проспекты, 79 (8555)30-87-94 (27нче номерлы ҖЭН каршында) | Бакый Урманче урамы, 29, 33, Тынычлык проспекты, 70, 72, 73, 75, 77, 74, 76, 81, 83, Төзүчеләр проспекты, 54, 56, 60, 64, 68 |
| 22 | «ТР ТКМР Башкарма комитеты мәдәният идарәсе» | 6нчы мәктәп, Тукай урамы, 15а (8555) 43-19-11 (28нче номерлы ҖЭН каршында) | Корабельная урамы, 4, 6, 12, 14, 14а, 14б, 20, 20а ул. Тукая,1, 3, 5, 5а, 7, 9, 31, 33, 35, Яшьлек урамы, 12, 14, 14а, 16, 18, 20а, 24, 26, 19, 21а, 21б, 21в, 21/16 Вокзал урамы, 2, 2а, 4, 6, 6а, 8, 10, 10а, 12, 14 |
| 23 | «Кама» СЙ ААҖ | 26нчы мәктәп, Шинчылар проспекты, 25а (8555) 36-18-77, 36-26-20 (29нчы номерлы ҖЭН каршында) | Вахитов проспекты, 43, 45, 51, Тынычлык проспекты, 3, 5, 7, 17, 23, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Шинчылар проспекты, 19, 21, 21а, 25, 27, 31, 33а, 35 |
| 24 | «Түбән Кама йөк шиналары заводы» ААҖ | 2нче татар гимназиясе, Бакый Урманче урамы,13, (8555)30-8785 (30нчы номерлы ҖЭН каршында) | Бакый Урманче урамы, 3, 9, 11, 19, 21, 23, 25, 31, Химиклар проспекты, 53, 57, Төзүчеләр проспекты, 36, 38, 45, 46, 50, |
| 25 | Мәгариф идарәсе (16нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе) | 16нчы мәктәп, Вахитов проспекты, 2а (8555) 43-26-88, 43-00-21 (31нче номерлы ҖЭН каршында) | Вахитов проспекты, 2, 4, 7, 9, 11, 15, 13, Чәбия урамы, 7, Менделеев урамы, 1, 1а, 1б, 3, 7, Прости авылы |
| 26 | «Е.Н.Королев исемендәгеТүбән Кама политехника көллияте» ДАҺББУ | «Е.Н.Королев исемендәгеТүбән Кама политехника көллияте» ДАҺББУ, Химиклар проспекты, 35 (8555) 36-83-99, 39-18-17 (33нче номерлы ҖЭН каршында) | Химиклар проспекты, 30, 30а, 30б, 32, 36, 36а, 36б, 36в, 36г, 38 Корабельная урамы, 24, 26, 28, Тукай урамы, 39 |
| 27 | Мәгариф идарәсе (27нче урта гомуми белем бирү мәктәбе) | 27нче мәктәп, Менделеев урамы,37а (8555)43-91-09 (34нче номерлы ҖЭН каршында) | Менделеев урамы, 23, 25, 31, 33, 35, 39, 41, Мурадьян урамы, 2, Вахитов проспекты, 32, Шинчылар проспекты, 36, 38, 43 |

| № ШСЧ БН | ШСЧ БНын җәелдерүгә җаваплы оешма | Аның базасында ШСЧ БН җәелдерелгән объект | ШСЧ БНна беркетелгән адреслар |
|---|---|---|---|
| 28 | «ТР ТКМР Башкарма комитеты мәктәпкәчә белем бирү идарәсе» МИ | 10нчы мәктәп, Чулман урамы, 18 (8555) 45-04-34, 45-03-99 (37нче номерлы ҖЭН каршында) | Сөембикә урамы, 51, 53, 55, 59, 61, 63, 65, 67, 69, 71, 73, 75, 77, 79,Чишмәле урамы, 1, 2, 3, 4, 4б, 6, 6/1, 7, 8, 9, 10, 11, 13, 14,15, 17, 19, Ямьле урамы, 2, 4, 6, 8, 10, Менделеев урамы, 47, 55 |
| 29 | Түбән Кама химия-технология институты (филиал) ФДБББУ ЮБ «КМТТУ» | Түбән Кама химия-технология институты (филиал) ФДБББУ ЮБ «КМТТУ», Төзүчеләр проспекты, 47, (8555) 39-2308 (39нчы номерлы ҖЭН каршында) | Студентлар урамы, 8, 8б, 10б, 14, Җиңүнең 30 еллыгы урамы, 16, 18, 20, 36, 38, 40 |
| 30 | «Н.В.Лемаев исемендәге нефтехимия һәм нефть эшкәртү техникумы» ДАҺББУ | «Н.В.Лемаев исемендәге нефтехимия һәм нефть эшкәртү техникумы» ДАҺББУ, Химиклар проспекты, 47/35, (8555) 39-19-09 (41нче номерлы ҖЭН каршында) | Төзүчеләр проспекты, 30, 32, 43, 44,<br>Студентлар урамы, 1, 3, 5, 5а, 9, 11а, 13, 15, 17,<br>Химиклар проспекты, 45а, 51,<br>Җиңүнең 30 еллыгы урамы, 2/39, 4, 6, 10, 12/19, |
| 31 | «ТТКХ һәм Т департаменты» МУПсе ( «ТКХП-17» ИК ААҖ) | 9нчы мәктәп, Спорт урамы,13б, (8555) 39-48-47, 3661-97 (43нче номерлы ҖЭН каршында) | Химиклар проспекты, 64, 66, 66а, 66б, 68,<br>Октябрьнең 50 еллыгы урамы, 2а, 4, 6,6а, 6б, 6в, 8, 8а, 8б, 10, 12 |
| 32 | «ТТКХ һәм Т департаменты» МУПсе ( «Жилтехсервис»ТКХ ИК ААҖ) | «13нче гимназия-интернат» МБББУ, Кайманов урамы,7, (8555)36-78-97 (44нче номерлы ҖЭН каршында) | Химиклар проспекты, 94, 96, 100, 102, 104, 106, 108, 110, 112, Урман урамы, 23, 25, Кайманов урамы, 3, 3а, 5, 11 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 33 | ТР ТКМР Каенлы авыл җирлеге администрациясе | «Каенлы урта белем бирү мәктәбе» МБББУ, Каенлы авылы, Мәктәп урамы, 17 (8555) 44-91-23 (45нче номерлы ҖЭН каршында) | Каенлы авылы, Байгол авылы, Байданкино авылы, Кече Җирекле авылы, Тоба авылы; Үчкә авылы, Борок авылы; Березовая Грива авылы, Яңа Минькино авылы, Красный Бор авылы |
| № ШСЧ БН | ШСЧ БНын җәелдерүгә җаваплы оешма | Аның базасында ШСЧ БН җәелдерелгән объект | ШСЧ БНна беркетелгән адреслар |
| 34 | ТР ТКМР Кызыл Чапчак авыл җирлеге администрациясе | «Югары Чаллы урта белем бирү мәктәбе» МБББУ, Югары Чаллы авылы, Яшьләр урамы, 5, (8555) 44-50-16 (46нчы номерлы ҖЭН каршында) | Кызыл Чапчак авылы, Түбән Чаллы авылы, Урта Чаллы авылы, Югары Чаллы авылы |
| 35 | ТР ТКМР Сухрау авыл җирлеге администрациясе | «Сухрау урта белем бирү мәктәбе» МБББУ, Сухрау авылы, Мәктәп урамы, 1 (8555) 44-11-16 (47нче номерлы ҖЭН каршында) | Сухрау авылы, Смыловка авылы, Сименеево авылы, Трудовой поселогы |
| 36 | ТР ТКМР Шәңгәлче авыл җирлеге администрациясе | «Шәңгәлче урта белем бирү мәктәбе» МБББУ, Шәңгәлче авылы, Яңа урам, 15, (8555) 43-04-64 (48нче номерлы ҖЭН каршында) | Шәңгәлче авылы, Кушай авылы, Ташлык авылы, Балчыклы авылы, Сарсаз Бли авылы, Келәтле авылы, Ключ труда поселогы, Биклән урманчылыгы, Кызыл юл урманчылыгы |

3нче кушымта

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 31 июлендәге
605нче номерлы карары белән
расланган

Төяү-бушату командасы составына эшчеләр бирүче оешмаларның
исемлеге

| № п/п | Икътисад объекты | Командаларның саны |
|---|---|---|
| 1 | “Түбән Кама нефтехим” ГАҖ | 5 |
| 2 | «Татнефть-Нефтехим» ИК ҖЧҖ | 7 |
| 3 | «ТТКХ һәм Т департаменты» МУПсе | 4 |
| 4 | « «Шинник СКХК» ҖЧҖ | 1 |
| 5 | «Шәһәр электр транспорты» МУПсе | 1 |
| 6 | «Эластик заводы» ҖЧҖ | 1 |
| 7 | «ТАИФ-НК» ААҖ | 1 |
| 8 | « «ТСНХРС тресты» ҖЧҖ | 1 |
| 9 | «Камэнергостройпром» ҖЧҖ | 1 |
| 10 | «Түбән Кама индустрия техникумы» ДАҺББУ | 1 |
| 11 | «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» | 1 |
| 12 | «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният идарәсе» | 1 |
| 13 | «Е.Н.Королев исемендәгеТүбән Кама политехника көллияте» ДАҺББУ | 1 |
| 14 | «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мәктәпкәчә белем бирү идарәсе» МИ | 1 |
| 15 | «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе” | 3 |
| 16 | Түбән Кама химия-технология институты (филиал) ФДБББУ ЮБ «КМТТУ» | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 17 | «Н.В.Лемаев исемендәге нефтехимия һәм нефть эшкәртү техникумы» ДАҺББУ | 1 |
| 18 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге администрациясе | 1 |
| 19 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге администрациясе | 1 |
| 20 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге администрациясе | 1 |
| 21 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге администрациясе | 1 |